# КАРАР

**25.11.2025ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Богады авылы җирлеге Яңа Җияш авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципалары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Иске Богады авылы җирлеге Яңа Җияш авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Иске Богады авыл җирлеге Яңа Җияш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар, көндезге формада укучылардан тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 1000 (бер мең) сум үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү системасын карап тоту һәм ремонтлау; җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү: («Шифа» чишмәсенең территориясенә материал сатып алу һәм койма тоту);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау).

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 82 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 53 граждан кертелде. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» позициясе өчен 53 граждан тавыш бирде;
"каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
"тоткарланучылар" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Богады авылы җирлеге Яңа Җияш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: "Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Иске Богады авыл җирлеге Яңа Җияш авылы территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар , көндезге формада укучылардан тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 1000 (бер мең) сум үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү системасын карап тоту һәм ремонтлау; җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү: («Шифа» чишмәсенең территориясенә материал сатып алу һәм койма тоту);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау).

3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге гражданнар Җыенының 25.11.2024 елда чыккан № 1 карарының 6 нчы пункты “Һәйкәлләр төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Яңа Җияш авылы һәйкәлләрен һәм обелискларын ремонтлау)”; 7 нче пункты “Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (контейнерлар сатып алу, Яңа Җияш авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү)” үз көчен югалткан дип танырга.

4. Иске Богады авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга - http://aktanysh.tatar.ru

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Актаныш муниципаль районы
Иске Богады авыл җирлеге Башлыгы Р.М.Ахметова